РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422050, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Шэмэрдэн авылы, Лермонтов
урамы, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

24.09.2018 № 21

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны
билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 24.03.2004 ел, №23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 13 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Шәмәрдән авыл җирлеге Советының «референдум үткәрү инициативасы турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 20 номерлы карары, Шәмәрдән авыл җирлеге Башкарма комитетының «референдум үткәрү инициативасы турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 52-п номерлы карары нигезендә, Шәмәрдән авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2018 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне раслау:

«2019 елда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Кырбаш авылында уен мәйданчыгы урнаштыру;
- Мичәнбаш авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау;
- Шәмәрдән авылында җирләү урыннарын карап тоту;

- Шәмәрдән авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау;

ЭЙЕ ЮК

3. Әлеге карарны «Саба таңнары» район газетасында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында, " Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар бастырып чыгарылган көннән үз көченә керә.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы А.Н.Гәрәев